Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№ 16 (29)

24 май 2012 ел

## Ике авыз сүз

21 май көнне ректор Илшат Гафуров житәкчелегендә Административ совет утырышы узды. Исегезгә төшерәбез: 26 апрель көнне узган Гыйльми советта биология һәм туфракны өйрәнү факультеты Фундаменталь медицина һәм биология институты дип үзгәртелде. Ректор утырышта катнашучылар игътибарына институт директорын – медицина фәннәре докторы, профессор Андрей Киясовны тәкъдим итте.

Алга таба Илшат Гафуров Кама дәүләт инженер-икътисад академиясен КФУ составына кушу эше яңа уку елына төгәлләнергә тиешлеген әйтте.

Кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе Сергей Ионенко кабул итү кампаниясенә әзерлек барышы белән таныштырды.

Җәй көне тәэзүчеләр өчен дә эш бик күп булачак. Хуҗалык эшләре буенча проректор Ленар Сафиуллин сүзләренә караганда, II корпустагы аудиторияләрдә ремонт булачак, шулай ук тәрәзәләрне һәм ике лифтны алыштыру планлаштырыла.

• • • •

16-19 май көннәрендә юридик атна кысаларында Санкт-Петербургта II Халыкара юридик форум үтте. Бирегә Россиянең Премьер-министры Дмитрий Медведев һәм Европа илләреннән, АКШтан дәүләт эшлеклеләре катнашты. Безнең Казан федераль университетыннан юридик факультет деканы Илдар Тарханов, аспирант Станислав Александров, шул ук факультет студентлары Тимур Какохо һәм Руслан Галиуллин эшлекле очрашуда булдылар. Форум дәвамында яшьләр белән берләктә юридик белем бирү үзенчәлекләре турында күп кенә фикер алышулар, кызыклы очрашулар, юрист һөнәренең төп миссиясе, җирлекләрнең үз хокукларын белмәүләре, юридик белемнәр буенча грамотасызлык турында дискуссияләр булды. Шулай ук бүгенге көндә юристларга эш табу мәсьәләсе дә читтә калмады. Безнең университет вәкиле Станислав Александров «Хокук мәктәбе» проектының Татарстан Республикасында тормышка ашырылуы турында чыгыш ясады. Руслан Галиуллин һәм Тимур Какохо шулай ук үзләренең секцияләрендә докладлар укыды.

• • • •

19 май көнне КФУ ректоры Илшат Гафуров «Спортивное вещание» оешмасының генераль директоры Василий Кикнадзе белән очрашты. Очрашуда, беренчедән, университетыбыздагы спорт тормышын RussiaSport.ru порталында яктыртып бару һәм, икенчедән, бу яңалыкларны күзәтү өчен, журналистларны нәкъ менә безнең вуз студентлары арасыннан сайлау мәсьәләләре каралды. RussiaSport.ru әле күптән түгел генә Мәскәү дәүләт университетының баскетбол финалы һәм Казан федераль университетының ректор кубогы матчларын трансляцияләгән иде. Тиздән, 2013 елда узачак Универсиадада спорт яңалыкларын яктыртып бару өчен, журналистика һәм социология факультеты студентларын сайлап алулар булачак.

• • • •

21 май көнне Казан федераль университетында «Фарма 2020» федераль программасын тормышка ашыру өчен уздырыла торган чаралар буенча Химик-технологик комплекс департаменты һәм РФ Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының биоинженерия технологияләре директоры Сергей Цыба катнашында җыелыш узды. Чарада КФУда фармацевтика һәм медицина юнәлешендә башкарылган эшләр һәм тормышка ашырылачак планнар турында мәгълүмат китерелде. Әлеге өлкә буенча фәнни-тикшеренү эшләре дә күпләп башкарыла. Докладларны тыңлагач, Сергей Цыба биргән сорауларның һәркайсына тулы җавап бирелде. Министрлык вәкиле галимнәрне грант һәм конкурсларда актив катнашырга, үз тәкъдимнәрен җибәрергә кушты һәм ярдәм итәргә сүз бирде.

• • • •

21-31 май көннәрендә, Төркмәнстан Президентының 2012 елның 29 мартында чыккан карары нигезендә, Төркмән җирлегендә халыкара фәнни экспедиция һәм «Төркмәнстан табигате: Койтендагның ачылмаган серләре» дигән темага конференция үтә. Экспедиция составында алты Россия галименең өчесе КФУдан. Галимнәр Төркмәнстанның көньяк-көнчыгыш ягындагы тауларда динозаврларның эзләрен өйрәнү, Койтендаг тауларындагы куышлыкларда, бу уникаль төбәктәге археологик объектлар, үсемлекләр дөньясы, күлләр, изге урыннарда тикшерү эшләре алып барачак.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



# Спорт + без = бергә!

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

**Яшьләр арасында спорт, аның белән шөгыльләнү, уңышка омтылу зур популярлык белән үсә. 22-23 май көннәрендә ел дәвамында барган җиңел атлетика буенча XXV вузлар арасында ачык студентлар уеннарының йомгаклау турлары узды.**

Дөнья күләмендә студентлар спорты тарихы бик ерактан башлана. 1905 елда АКШта беренче тапкыр студентлар арасында халыкара ярышлар үтә. 1949 елда Мәскәүдә беренче мәртәбә булган ярышлардан соң, Россиядә бу бераз тукталып тора. 1958 елдан яңадан уздырыла башлаган ярышлар студентлар арасында зур кызыксыну уята. Шулай итеп, Олимпия уеннары программасы буенча спорт чаралары оештырыла башлый.

Татарстаныбызда да әлеге уеннарга зур игътибар бирелә. Чараның төп максаты булып студентлар арасында спортны җәелдерү, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, иң көчле спортчылар һәм командаларны барлау тора.

XXV ачык студентлар уеннары барышында, 29 спорт төрендә ярыштылар. Армспорт, татарча көрәш, бадминтон, җиңел атлетика, кикбоксинг, бильярд, йөзү кебек төрләр буенча студентлар арасында иң көчлеләр билгеләнде.

Ярышларның төп судьясы Светлана Вострикова сүзләренә караганда, студентлар быел тагын да ныклап әзерләнгән, ярышларга җитди караган, чөнки көрсәткечләр бик югары. «Башта уку йортлары арасында эчке сайлап алу турнирлары узды, ягъни көчлеләр арасыннан иң-иңнәр сайланды. Быелгы ярышлар ачык дип игълан ителде, шуңа күрә Татарстанның барлык югары уку йортлары студентлары да катнаша алды», – дип фикерләре белән уртаклашты ул. Студентлар гына дип ассызыклау дөрес булмас, чөнки чарада ветеран-спортчылар да бик теләп катнашты.

Җанатарларның да зур активлык күрсәтүе – матур күренеш. Алар үз спортчыларына, командаларга көч биреп торды. Шунысы куанычлы: җиңүчеләр арасында күпчелекне Казан федераль университеты студентлары алды. Бу җиңүләр тагын бер кат студентларның сәламәт яшәү рәвешенә зур игътибар бирүе, спорт белән даими шөгыльләнүе турында сөйли. Уку йортыбызга дан-дәрәҗә алып килгән студентларны җиңүләре белән котлыйбыз. Тагын да яхшы күрсәткечләргә ирешүегезне телибез!

## Эшлекле сөйләшү

# Җир маен - заманча!

**Динә МӨХТӘСИПОВА,**
хәбәрче

**Кичә, ягъни 23 май көнне Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институтында кара алтын продуктларын анализлый торган заманча җиһазларга багышланган семинар узды.**

Семинар кысаларында «Сотрейд компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять хезмәткәрләре геологиядә кара алтынның, керн һәм башка геологик объектларның төрле характеристикаларын анализлауда кирәкле булган җиһазлар турында лекция укыды. Моннан тыш семинарда катнашучылар төрле үрнәктәге изотопларны анализлауда кулланыла торган җиһазлар белән дә танышты.

**Ахыры 3нче биттә.**



Әмир Фазлыйәхмәтов фотосы

Фән дөньясында

# Яңа модель булырмы?

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

Казанда педагогик белем бирүгә 200 ел тулу уңаеннан, КФУ ның Педагогика һәм психология институтында 21-23 май көннәрендә «Модернизация шартларында педагогик белем бирүдә инновацияләр, көндәшлеккә сәләтле шәхеснең үзүсеше проблемалары» дигән темага Халыкара фәнни конференция эшләде.

22 май көнне Лобачевский исемендәге китапханәдә шул нисбәттән зур чара узды. Пленар утырышны сәламләү сүзе белән уку-укыту эшләре буенча проректор, социология фәннәре докторы, профессор Рияз Минзарипов һәм Педагогика һәм психология институты директоры, тарих фәннәре докторы, профессор Айдар Кәлимуллин ачып җибәрде. Айдар Кәлимуллин Казан Император университетында 1812 елда тәүге тапкыр Педагогика институты оешуын, Идел буенда педагогик белем бирүгә быел инде 200 ел тулуын аерым билгеләп үтте.

Чыгыш ясаучылардан академик, педагогика фәннәре докторы, профессор В.Андреев, профессорлар Җ.Нигъмәтов, Г.Габдуллин һәм В.Каташев, Белем бирү департаменты директоры, профессор Г.Ившина, Телләр институты профессоры Ф.Ратнерны конференция делегатлары аерым бер игътибар белән тыңлады, чөнки һәр чыгыш XXI гасырда педагогик белем бирүнең актуаль проблемаларын чишү юлларын күрсәтүдән гыйбарәт иде.

Конференция кунаклары арасында Самара, Сочи, Мәскәү, хәтта Кытайдан да вәкилләр булды.

Хәзерге көндә Россия педагогик вузларында укучы студентлар 20-30 елдан илебездә белем бирүнең сыйфаты ни дәрәҗәдә булуын күрсәтәчәк. Шуңа күрә дә XXI гасырның яшь буынын укыту, тәрбияләү – булачак педагогларның һөнәри осталыгыннан, интеллигентлылыгыннан, замана студентының иҗади потенциалыннан тора. Статистик мәгълүматларга карасак, студент үз вакытының 10% – уку йортында, ә калган 90% вуздан тыш үткәрә. Алар аз укыйлар, театрларга йөрмиләр диярлек, гомумән, үзләренең яшәү сыйфаты турында уйламыйлар. Студент күп очракта – кулланучы. Әле беркайда эшләмәгән килеш, күбесендә иномарка... Шуңа күрә аларда иҗади эшчәнлекнең контекстта төрле төрләрен, мәгънәвикыйммәти ориентацияләрне, үз-үзеңне камилләштерү, югары әхлаклылык, интеллигентлылык, көндәшлеккә сәләтле шәхес булуны һ.б. формалаштырырга кирәк. Бу сыйфатлар, беренче чиратта, укытучының үзендә булырга тиеш. Әгәр укытучы һәрдаим үсештә икән, аның студентлары да шундый була. Нинди соң ул замана укытучысы? Безгә яңа концептуаль идеяләр һәм яңа дәреслекләр әзерләргә кирәклеге һ.б. турында зур сөйләшү булды.

«Көз көне зурлап уздырылачак олы юбилей алдыннан үткәрелгән бу чара педагогик белем бирү өлкәсендә бик мөһим вакыйга. Безнең сөйләшү әле башлана гына. 3-5 октябрь көннәрендә булачак конференциягә дә көтеп калабыз», – диде Педагогика һәм психология институты директоры А.Кәлимуллин.

Соңгы кыңгырау

# «Әлбәттә, калыгыз!»

**Динара ӘХМӘТОВА,**
**Анна КИРПИЧНИКОВА,**
хәбәрчеләр



22-23 май көннәрендә Казан федераль университетында Кече университетны тәмамлаучыларның чыгарылыш кичәсе узды.



Әмир Фәзлыйәхмәтов фотолары

Матур итеп киенгән, зурларча фикер йөртүче унберенче сыйныф укучылары бу көнне үзләрен бик җитди тотты. Араларында 8 нче, 9 нчы сыйныфлардан ук бирегә килгән, 10-11 сыйныфтан гына югары уку йортында кайный башлаганнары да бар иде. Ничек кенә булмасын, алар инде дуслашып, «бер гаилә» кешеләренә әверелеп беткәннәр. Зачет-имтиханнарның ни икәнен дә яхшы аңлый, укытучы белән студент мөнәсәбәтен ничек җайларга кирәклеген дә белә.

Чара вузга кадәр белем бирү факультеты деканы Наталья Калачеваның сәламләү сүзләре белән башланып китте: «Биредә алган тәҗрибәгез сезгә киләчәктә дә ярдәмгә килер дип ышанабыз. Иҗади уңышлар һәм ирешелгәннәрдә генә туктап калмавыгызны телим», – диде.

Кече университет 30 елдан артык мәктәп укучыларын студент тормышына, зур фән дөньясына әзерли. Яшь студентлар төрле фәнни-тикшеренү конференцияләрендә катнашып кына калмый, хәтта оештыруда да активлык күрсәтә.

Дулкынландыргыч мизгел – таныклык тапшыру вакытында укучы-студентларның йөзендә шатлык нурлары балкыды. Бу бит, Кече уку йортын тәмамлаганны исбатлый торган документ булудан тыш, зур, мөстәкыйль тормыш ишекләренә ачкыч та әле. Кая барырга, нинди өлкә буенча һөнәр сайларга дип икеләнеп торасы да юк. Әлеге уку йорты физика-математика, химия-биология, филология һәм җәмгатьчелек факультетларының нәни студентларын һәрчак үзендә көтеп кала.

Укучылар үзләре дә университет тормышында кайнарга ярдәм иткән укытучыларына рәхмәт сүзләре җиткерде һәм «Без бик теләп калыр идек...» дигән матур җыр башкарды.

Җырга каршы: «Әлбәттә, калыгыз!» – диясе килә. Ләкин чын студентлар сыйфатында!

«Казан утлары»на – 90



■ Журналның баш мөхәррире Р.Фәйзуллин чыгыш ясый

# Аксакал журнал

**Рамил ХАННАНОВ**

Узган атнада академик басмабыз – «Казан утлары» журналы үзенең 90 еллык юбилеен билгеләп үтте. Бәйрәм чаралары Филология һәм сәнгать институтында «Казан утлары» журналы һәм милли мәдәният» дип аталган Түгәрәк фәнни-гамәли конференция белән башланып китте.

Фәнни җыенда татар халкының күренекле әдипләре, галимнәре һәм студентлар катнашты. Чараны ачып җибәргән Филология һәм сәнгать институты директоры Рәдиф Җамалетдинов «Казан утлары» журналының татар әдәбиятын, мәдәниятен һәм сәнгатен үстерүдәге, саклаудагы алыштыргысыз үз юлы булуын билгеләп үтте. Галимнәребез Хатыйп Миңнегулов, Тәлгат Галиуллин, Фоат Галимуллиннар басманың төрле юнәлешләрдәге эшчәнлеген кызыклы докладларда ачты. Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары Нурия Беломоина исә бүгенге татар матбугатының торышы, үсеш перспективалары һәм мөмкинлекләре хакында сөйләде.

Чараның тантаналы өлеше кич белән Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында булды.

Безнең юбиляр

# Алты дистәнең алты мизгеле

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Университетыбыз галиме, хәзерге татар теле һәм укыту методикасы кафедрасы профессоры Фираз Фахраз улы ХАРИСОВ шушы көннәрдә зур юбилеен билгеләп үтә. Аның иң истәлекле тормыш мизгелләрен тәкъдим итәбез.

*Мин үземне шушы фани дөньяга килгән көнемнән үк бик бәхетле дип уйлыйм. Беренчедән, әтиәнием аң-белемле, тәрбияле, Каюм Насыйри, Мәрҗани кебек шәхесләр язганча, дөрес итеп, тиешле дәрәҗәдә бирделәр! Без гаиләдә 4 малай үстек. Бүген дүртебезнең дә үз урыны, үз дәрәҗәсе бар. Икенчедән, күпсанлы шәхесләр чыгарган Башкортсан Республикасы Яңавыл районында туууым да күңелемә янә бер куаныч, горурлык хисләре өсти!..*

*Мәктәптә уку, эшләү еллары, Төркмәнстанның Небит-Даг шәһәрендә авиация полкында хезмәт итүем – шәхес буларак формалашуга юнәлгән адымнарым – гомер фасылымның икенче дистәсенә туры килә... Бу вакыт аралыгында мин чын мәгънәсендә чыныгу тәҗрибәсе алдым.*

*Аннан соң тормышымның иң мөһим этабы тормыш иптәшем, якын дустым, хезмәттәшем Чулпан Мөхәррәм кызы белән танышу булгандыр, мөгаен... Ничегрәк булды соң ул? Ул вакытта Губкин урамындагы тулай торакта яшәдек. Кайбер көннәрдә зур залда*



*фильмнар күрсәтәләр иде. «17 мгновений весны» аеруча популяр булды. Фильм карарга төшкән саен, я ул минем янда утыра, я мин аның янына барып утырам, я бер-беребезгә урын алып кала идек. Шулай өч-дүрт ай дуслар булып йөргәннән соң, мин, бар кыюлыгымны җыеп, Чулпанны «Дружба» кинотеатрына чакырдым. Дуслык мәхәббәт хисләренә әйләнде. Өч ел очрашып йөргәннән соң, без гаилә корып җибәрдек...*

*Тагын да куанычлырак мизгелләр балалар тугач булды. Илшат белән Гөлшат беркайчан да йөзебезгә кызыллык китермәде. Бәлки аларга игътибар да җитеп бетмәгәндер, кичләрен төрле диссертацияләр, фәнни эшләр язганда, янәбызда бөтерелеп йөреп, барысын да күреп үстеләр. Зуррак үсә төшкәч, мәктәп укучыларына дәреслекләр язар алдыннан, башта биремнәрен балаларга күрсәтә идек. «Әти, бу авыррак, мәктәптә укучылар өчен катлаулы булыр», – дисәләр, биремнәрне яңадан үзгәртеп эшләдек. Шушы мохит аларны үзе тәрбияләде. Аллага шөкер, бүген балаларыбыз белән чын мәгънәсендә горурланабыз! Игелекле, тәрбияле булулары, үз урыннарын үзләре таба белүләренә куанабыз!*

*Әлбәттә, педагогик белем бирүче уку йорты минем өчен аерым бер этапны алып тора. Тормыш биографиямдә студент булуым да, аспирант, ассистент, докторант, кафедра мөдире һ.б. вазифаларны башкаруым да югары педагогик белем бирүче уку йорты белән бәйләнгән. Минем өчен бу уку йорты тормыш тәҗрибәсе, шәхес, педагог булуымда зур роль уйнады. Шулай ук диссертацияләр, дәреслекләр, татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлекләр – аларның һәммәсенә күпме көч, хезмәт куелган. Һәрберсе аерым бер шатлыклы мизгел!*

*Җиде-сигез ел элек авылыбызда классташлар очрашуы булып узды. Ул Сабантуй көненә туры килгән иде. Ә мине районга чакыралар. Ничек инде классташлар янына кайтмыйм? Ничек инде классташлар янына кайткан җиремнән китеп барыйм, ди?! Калдым... Барысы да җыелганнар, һәрберсе белән исемләп күрешәм. Үз исемнәре белән эндәшкәч, «Фираз мине таныды», «Әле дә хәтерли икән», дия-дия, балаларча сөенеп, мине шаккатырганнар иде. Үзем гап-гади алар шикелле үк кеше бит инде. Күрәмсең, Казанда эшләвем, ниндидер үрләр яулавым алар өчен башка сыймаслык хәлгә ирешкәндәй булгандыр...*

*Кайвакыт гаиләбез белән шәһәр читендәге бакчабызга китәбез. Анда чын-чынлап ял итеп, утырткан агачларымны, яшелчәләрне карап, яшеллеккә сокланып, тагын да рухланып кайтам. Шушындый җан тынычлыгы алуыма һәрвакыт теләктәшлек, ярдәм күрсәтеп торучы Чулпанның янымда булуы да зур роль уйнагандыр. Аннан башка үземне кеше буларак та, шәхес буларак та күз алдына китерә алмыйм...*

*Инде менә алтынчы дистәне дә ваклап килям. Ә 60 яшь тулуына мин үзем дә, дус-ишләрем дә ышанмыйлар. Күңел һаман да яшь чактагы кебек. Рухланып эшлисе дә эшлисе килә! Ходай саулыктан гына аермасын иде!*

● Җиңүнең 67 еллыгына

# Дәһшәтле еллар кайтавазы

**Роза ХӘМИТОВА**

Заманында безнең университетта белем алган Роза Хәмитова – сугыш елы баласы. Аның хатирәләрендә дәһшәтле сугыш нинди эз калдырган?! Юк, аның гына түгел, ә бөтен сугыш чоры балаларында... Көндәлек битләрендә – ачы хакыйкать.

***(Ахыры. Башы алдагы саннарда.)***

Әнием мине Кама Тамагына алып килде. Икетуган апам Раида тәрәзәгә карады да: «Немецлар килә!» – дип кычкырды. Мин шундук куркуымнан караватастына кереп качтым. Ә апаларым курыкмыйлар. Мин дә, алардан үрнәк алып, тәрәзәгә күз салам. Урамда шомлы тынлык. Бер төркем немец солдатлары тыныч кына атлап баралар.

Юл кырыендагы капкалардан апалар да тыныч кына фашист солдатларын алып киткәнне карап торалар. Тоткыннарның йөзендә шатлыкның, елмаюның әсәре дә юк. Бүлмәгә Гандалиб апа керә дә: «Безнекеләрне дә кайдадыр шулай алып баралардыр инде», – ди...

*1944 ел, иртә көз*

*Биш ел, биш ай...*

1945 елның май иртәсендә күк йөзендә кояш юк иде. Шуңа карамастан әнием ал төстәге ефәк күлмәген киде. Менә ул чыннан да кояшны алыштыра иде! Күлмәк инде бик озак вакытлар сандыкта ятты, менә ниһаять аның да вакыты җитте. Май. Язгы чәчү. Барлык халык кырда булырга тиеш. Шулай да Җиңү бәйрәме хөрмәтенә колхозчылар мәктәп янына җыелганнар. Барчасы да яшел үләнгә утырып, минем ал күлмәкле әниемнең Җиңү турындагы докладын тыңлыйлар. Докладны карап, игътибар белән укый әнием, чөнки бер артык сүз ычкындырырга ярамый...



Без бала-чагалар – Фәридә һәм Мәрхәбә – кырыйда гадәттәгечә басып торабыз, бездән башка бер генә колхоз җыелышлары да үтми дисәм, һич тә ялган булмас. Куанабыз! Нәҗип әйтә: «Гитлер асылынган, шул кирәк тә инде аңа!» Ә икенче Нәҗип аны төзәтә: «Юк, ул асылынмаган, ул үз-үзенә аткан». Гитлер безнең төп дошманыбыз иде. Нәкъ менә аның аркасында Саниянең, Миңнегөлнең, Люция, Лиза, Нюра, Коля, Райка һәм Хәйдәрләрнең әтиләре һәлак булды.

Тиздән, инде бик тиздән Һади абый, Җәләл абый, Галимулла абый, әнинең абыйлары, әтием, Исмәгыйль абзам (мине бик тә аңа охшаган, диләр) да кайтырга тиеш... Без барыбыз да – Бикәй авылының балалары – һәрчак тузанлы юлларны күзәтәбез... Көтәбез, көтәбез, бөтен җаныбыз белән бары тик көтәбез...

*1945 ел. Май*

● Кечкенә галимнәр

# Истәлекләрнең дә була төрлесе...

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Сәхифәбезнең бүгенге кунагы – филология фәннәре кандидаты, Филология һәм сәнгать институты тәрҗемә белеме һәм мәдәниятара коммуникацияләр бүлегенең тәрҗемә теориясе һәм сөйләм коммуникацияләре кафедрасы доценты Николай Валентин улы МАКСИМОВ.



«...Мин үзем кечкенә чактан ук галимлек сыйфатлары күрсәтә башлаганмын. Шулай бервакыт без татар теленнән диктант яздык. Шунда «класста» дигән сүзне юлдан-юлга «клас-ста» дип күчергәнмен. Шул бер хата өчен укытучы миңа дүртле билгесен куйган иде. Мин инде уйлап-уйлап тордым да укытучыга: «Сез минем эшне дөрес тикшермәгәнсез», – дидем. Ул миңа уйчан күзләре белән карап-карап торды да: «Юк, энем, син үзең дөрес әйтмисең», – ди. Шулай да мин бирешмәгәнмен, карышканмын, кыскасы, шушы хата аркасында без аның белән уртак тел таба алмадык. Шуннан соң кич белән ул минем дәфтәрне күтәреп өйгә килгән. Ишегалдында йөргән җиремнән, укытучыны күреп, шыпырт кына чыгып киттем. Ә ул өйгә кереп әти белән әнигә шул «класста» сүзенең юлдан-юлга язылышын исбатлый икән. Әти дә колхозчы, әни дә колхозчы – алар инде укытучыга бер сүз дә каршы эндәшмәгәннәр. Өйгә кайтып кергәч, миңа хәйран гына сабак укыдылар. Мин әле аннан соң да ышанмадым, үз эчемнән һаман иҗекләргә бүлеп йөрим: «клас-ста», «класс-та»... Кем белгән аның ул чагында «класс» сүзенең тамыр икәнен! Шул рәвешле, үземчә бер ачыш ясаганмын. Укытучы өчен ачыш булмаган инде. Уйлап-уйлап куям да, димәк, мин нәрсәнедер шул яшьтән үк исбатларга омтылганмын.



■ *Рәсемдә: Н.Максимовның (уңда) бала чагы*


Студент елларына килгәндә, минем 5 ел укып бер генә тапкыр да дүртле билгесе алганым булмады. Ләкин, дәүләт имтиханында татар телен укыту методикасыннан дүртле куйдылар. Сәбәбе кызыл диплом бирергә теләмәү иде... Иң яраткан, иң теләп укыган фәнемнән шулай килеп чыгуы, әлбәттә, күңелнең нечкә җиренә үтеп керде. Шуңа да һәрчак укытучылар, дәүләт имтиханнарын кабул иткәндә, игътибарлы, үз эшләренә җаваплы карасыннар иде дип телим!..»

● Алар бездә укыган

# Сүз моңы

**Регина РАЯНОВА,**
татар филологиясе бүлеге студенты

Еллар үтеп, гомер көзенә якынлашкан саен, кеше яшьлеген ныграк искә төшерә, аны сагына башлый. Ул вакытта аңламыйча гына кылган ялгышлар, хаталар да кадерле, күңелгә якын булып тоела. Татарстан һәм Башкортстанның атказанган фән эшлеклесе, филология фәннәре докторы, профессор, Башкортстанның халык язучысы, безнең редакция белән һәрчак элемтәдә торган Суфиян ага Поварисов әлеге хатында нәкъ менә шул турыда, ягъни Казан педагогия институтындагы беренче татар теле дәресен исенә төшерә.



«1951 ел. Мин – Казан дәүләт педагогия институтындагы татар теле һәм әдәбияты бүлеге студенты. Менә беренче дәрес, Фатыйма апа Вәлиева килеп керә. Аягөсте басып каршы алабыз. Утырырга кушкач, һәркем үз урынына җайлашты. Ул гамәли занятие үткәрәчәге турында әйтте. Эшне диктант язудан башларга тиешбез икән. Монысы урта мәктәптә алган белемебезне чамалау өчен, янәсе. Башта ул текстны укып чыкты. Бик матур, килештереп, һәр сүзне, һәр хәрефне берникадәр моңлы итеп әйтә.

Берничә көннән соң янә аның дәресе. Килеп керә бу. Басып каршы алабыз. Ачык йөзе, мөлаем карашы белән әсир итә безне. Диктантны тикшерүе турында әйтте дә, мине тактага чакырып, «әдәбият» дигән сүзне язарга кушты. Мин «адабиат» дип язып куйдым. Фатыйма апа әле миңа, әле студентларга карый. Гаҗәпләнә. Башын селкеп куя. Күзләре тоздай булды. Студентлар да шул ук халәттә. «Үзе әдәбиятны өйрәнергә килгән. Үзе шул сүздә дүрт хата җибәргән. Җитмәсә, имтихансыз үткән бит әле хәйләкәр төлке», – ди иде аларның күзләре. Фатыйма апа белән безнең арада шундыйрак сөйләшү булып алды:

– Мин сезгә «әдәбият» дип язарга куштым бит.

– Яздым бит инде.

– Сез бит «адабиат» дип яздыгыз.

– Бездә шулай язалар аны.

– Кайда ул сездә?

– Үзбәкстанда.

– Сез анда укыдыгызмыни?

– Әйе.

– Нинди телдә?

– Үзбәк телендә...

Студентлар, хор белән дигәндәй, кычкырып көлеп җибәрде.

Мәсьәлә шунда: мин, чыннан да, бер үзбәк мәктәбендә җиде ел белем алып, хәрби җитәкче (военрук) булып эшләдем. Бер үк вакытта үзлегемнән укып, 1955 елда кулга аттестат алдым. Ул елларда фронтовик урта мәктәпне гел «отлично»га тәмамласа, теләсә нинди вузга имтихансыз алына иде. Мин – шул гаскәрнең бер солдаты. Диктантта 200 гә якын хата җибәргәнмен.

Минем өчен кызу, кайнар, тынгысыз шөгыль башланды. Төркемдәшем Равил Сәгъдиев укытучым булып китте. Көн дә диктант яздыра. Ул нык борчыла. Минем йөрәктә дә «Прометей уты» кайный. Мин аны «остаз, мөгаллим», дип атадым. Ә ул мине «шәкертем» дип йөрде. Ел азагына зачет өчен диктант язгач, унлап хата җибәрүчеләр булды. Күпме генә тырышып эзләмәсен, Фатыйма апабыз минем диктанттан бер генә хата да таба алмаган. Аллага шөкер! Солдат ныклыгы булгандыр бу, бәлки. Сүз моңын кыз моңы кебек яратса, егет кеше тел оҗмахында адашмый икән».


● Эшлекле сөйләшү

# Җир маен - заманча!

**Башы 1нче биттә.**

Шулай ук Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институтының сыйфат менеджменты һәм маркетингы, өстәмә белем бирү үзәге «ГЕОТЕК-Холдинг» ябык акционерлык җәмгыяте белән берлектә 23 майдан 1 июньгә кадәр квалификацияне арттыру буенча дисциплинарара уникаль курслар үткәрә. Курслар вакытында «ГЕОТЕК-Холдинг» җәмгыятенең 79 хезмәткәре белемен арттырачак.

Чарада Sercel компаниясенең (Франция) алдынгы белгечләре, Россиянең төрле оешма вәкилләре, геофизика, икътисад, психология, экология һәм информатика буенча укытучылар катнашачак. 1 июнь – документлар тапшырган көнне «ГЕОТЕК-Холдинг» ябык акционерлык җәмгыяте президенты Марио Русев килер дип көтелә. Курста катнашучылар өчен интенсив укыту программасыннан тыш, мәдәни-күңел ачу, спорт чаралары да оештырылачак.



Әмир Фазлыйәхмәтов фотосы

**РАБОТА СТУДЕНТАМ и ДИПЛОМНИКАМ**

НПФ БЛАГОСОСТОЯНИЕ

В один из крупнейших Российских негосударственных пенсионных фондов НПФ «БЛАГОСОСТОЯНИЕ» (российские железные дороги) требуются сотрудники на должности финансового консультанта и руководителя группы.

• оформление по договору,
• гибкий график работы, возможность совмещения,
• оплата своевременная, обучение за счет компании,
• **оклад до 20 000** +премии(оклад по результатам собеседования),

Требования: аккуратность, активность, коммуникабельность, желание зарабатывать.
**Опыт работы не обязателен !!!**

**СТУДЕНТ - НЕ УПУСКАЙ ВОЗМОЖНОСТЬ - ЗАРАБОТАТЬ И ПОЛУЧИТЬ ПЕРВОНАЧАЛЬНЫЙ ОПЫТ РАБОТЫ В СВОБОДНОЕ ОТ УЧЕБЫ ВРЕМЯ!!!**

**Все подробности:**
**г.Казань, ул Московская, 31/6, офис 203**
**или по телефонам:**
**(843) 240-18-14, 259-18-89**
**http://www.vasheblagosostoyanie.ru/**

реклама

● Балалар дөньясы

# Тылсым илендә

Динә МӨХТӘСИПОВА,
хәбәрче

«Тылсымлы куллар» журналының май аенда 3 нче саны дөнья күрде. Бай эчтәлекле, нечкә зәвык белән эшләнгән өлеге журналны, һичшиксез, һәр сабый түземсезлек белән көтеп алады. Журналның баш мөхәррире, филология фәннәре кандидаты Ландыш Хәмит кызы ФАЗУЛЛИНА нинләр белән янып йөри икән? Үзенә мөрәҗәгать иттек.



**– Укучыларны алдагы ертыеллыкта нәрсә белән шаккатырмакчы буласыз?**

– Әти-әниләрнең үтенече буенча, июль аеннан журналыбыз ай саен чыга башлый. Бу хәбәр күпләрнең күңеленә хуш килер дип уйлыйм мин.

**– Журналда нинди сәхифәләр бар?**

– «Тылсымлы остаханә», «Тәмле булсын», «Илһам чишмәсе», «Серләр сандыгы», «Тапкырлар аланы» һ.б. сәхифәләр балаларыбызны хезмәткә өнди, татар әдәбиятына, мәдәниятенә мәхәббәт тәрбияли, логик фикерләү сәләтен үстерергә ярдәм итә. «Сихәтле белем» сәхифәсендә уен рәвешендә дини тәрбия дәресләрен тәкъдим итәбез. Тамчыдан күл җыела, дип юкка әйтмәгәннәр. Тамчы булып яуган дин сабаклары балаларыбызның күңеленә шифа бирер, иманнарын ныгытыр. Физик мөмкинлекләре чикле булган сабыйларга да сәхифә багышлавыбызга сөенәм. Ходай Тәгалә бу изге җаннарга һәм аларның әти-әниләренә сабырлык һәм көч бирсен иде. Тырышып, авыртуларга түзеп, югары күрсәткечләргә ирешкән балалар турында мәгълүмат даими басылып барачак. Журналыбызның соңгы ике битендә башлангыч сыйныф укытучылары һәм тәрбиячеләрнең ачык дәресләрен бастыруга да урын бирелә. Бу, үз чиратында, педагогларыбызга тәҗрибә уртаклашырга ярдәм итәр.



■ Кол Шәриф мәчетендә очрашу

**– Журналның исеме җисеменә туры киләме?**

– Сабый чакта һәркем тылсым дөньясында яши. Куллар ярдәмендә бала әйләнә-тирә мохитне өйрәнә. Аңа бар да кызык. Гүзәллекне күреп, берсеннән-берсе матур кечкенә иҗат «әсәрләре» тудырса, эшләгән эшенә уңай бәя алса, ул үзенең уңышына чиксез шатлана һәм яңадан-яңа фикерләр белән канатлана. «Тылсымлы куллар» журналы балаларга хезмәтне яратырга өйрәтә, аларны әти-әниләре белән тагы да якынайта. Бүгенге заманда сабыйларыбызга игътибар кими. Кесә телефоны, компьютер, телевизор ата-анага баласын «тәрбияләүдә» ярдәмгә килә. Тавыш-тынсыз үзенә шөгыль тапкан баланың ничек итеп уйный белү сәләтеннән мәхрүм ителгәнен белсә иде алар! Көнгә 10-15 минут журнал укып, кул эшләре белән шөгыльләнү, дини сабак алу, балалар әдәбияты, милли традицияләребез белән танышу, логик биремнәр чишү балаларга гына түгел, зурларга да файдалы.



**– Журналга ничек язылырга була? Чит төбәкләрдән дә язылучылар бармы?**

– Бүген «Тылсымлы куллар» журналына Татарстан Республикасында гына язылырга мөмкин. Индексы – 83078. Чит төбәкләрдән язылырга теләк белдергән милләттәшләребез дә шактый. Әйтик, Самара, Уфа, Богрыслан төбәкләренә журналны почта аша үзебез җибәреп торабыз.

**– Эш уңышлы барып чыксын өчен, нинди рецепт кулланырга?**

– Иң элек Ходайдан һәр эшнең хәерле ягын насыйп итүен сорарга. Булмый, барып чыкмый дигәннәрнең сүзләрен колакка да элмәскә. Эшеңне яратып башкарырга, актив, эзләнүчән булырга, ирешелгән белән чикләнмичә, яңа максатлар куеп яшәргә кирәк. Шулчак бәлешең дә тәмле булыр, эшең дә уңар!

**– Җылы әңгәмәгез өчен зур рәхмәт Сезгә! Алга таба да уңышлар телибез!**

реклама




● Сәламәтлек

# һәр «плюс»ның үз «минус»ы

Зилә ФӘСХИЕВА,
хәбәрче

Бүгенге көндә кояш хәтта астрономия өлкәсендә дә иң аз өйрәнелгән. Бер генә ил галимнәренең дә кояш әйләнәсенә спутникларны якын китерә алганы юк...

Шуңа карамастан, белгечләр арасында да, гади кешеләр арасында да кояш астында йөрү турында бик күп каршылыклы фикерләр бар. Берәүләр кояш нурларының кеше организмы өчен бернинди зыяны да булмау турында сөйләсә, икенчеләре исә эссе көннәрдә ачык һава астында йөрү сәламәтлеккә бик нык зыянлы дип саный.

Кайбер мәгълүматлардан чыгып карасаң, төньяк зоналарда яшәүче кешеләр көньяктагыларга караганда яман шеш авыруы белән күбрәк чирли икән. Моның сәбәбен организмга кирәкле Д витаминының җитешмәвендә дип күрсәтәләр. Чыннан да, әгәр организмыбызга кояштан ала торган Д витамины җитмәсә, бик күп авырулар килеп чыгарга мөмкин. Ничек тәэсир итә соң ул? Д витамины начар күзәнәкләрнең үсүенә комачаулый һәм организмга кирәксез күзәнәкләрнең вакытында үлеп баруын тәэмин итә. Кызганычка каршы, Россиянең күп кенә зоналары «Д витамины җитәрлек дозада булмаганнар» исемлегенә кертелгән. Көз айларыннан язга кадәр организм кирәкле кояш нуры витаминнарын «куллана» башлый һәм аның күләме кан составында бик аз кала. Шул ук вакытта күпчелек кеше үзенең 93% вакытын ябык биналарда, офисларда үткәрә, бу, әлбәттә, ультрофиолет нурларына юлны ябып куя. Без ашый торган ризыкларда мондый витаминның булуы күрсәтелсә дә, ул инде тиешле дәрәҗәдә түгел.



Кояш нурларының әһәмиятле булуы һәм ансыз организмның хәлсезләнүенә төшендек шикелле. Ләкин шулай да һәрбер «плюс»ның үз «минус»лары да бар. Дерматологлар кояшта озак вакыт дәвамында торуның ике зур кимчелеген күрсәтә: беренчедән, организм, тән тиресе картая, икенчедән, тән тиресендә яман шеш авыруы барлыкка килү куркынычы бермә-бер арта төшә. Әгәр дә тәндә күренеп торган миңнәр булса, бу урыннарны алар аеруча саклап йөрергә киңәш итә. Һәм шуны истә тотарга кирәк: һәрбер кешенең организмы – ул уникаль, берәүләр көне буе кояш астында торса да, үзгәрешләр сизмәскә, ә икенчеләр ярты сәгать кояшта торудан үзләрендә хәлсезлек тоярга мөмкин. Ачык тәнле кешеләргә ультрафиолет нурларының файдасына караганда, зарары күбрәк булуын дәлилләгән мисаллар да бар. Шуңа күрә кояшта кызынучыларга дозасын белү һәм «аздан – күпкә» принцибын истә тоту бик мөһим.

Фикерләр дә, исбатланган дәлилләр дә төрле... Ә кояш нурларын куркыныч факторга әйләндермәү бары тик үзебездән, чама хисен белүдән тора!




DARELFӨNYN университет
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.